ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.10.2019 | с. Кильдеево | 2

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Харино авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 5 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Харино авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Харино авылының су башнясының беренче санитар зонасын коймалау һәм төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Харино авылы, Нагорная урамы, 7А йорт адресы буенча урнашкан кибет янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Килди авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин